МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.10.2022 г.Казань № 928

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Өлкән яшьтәге гражданнарның (инвалидларның) читләр каравына индивидуаль ихтыяҗын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 9 сентябрендәге 646 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Өлкән яшьтәге гражданнарның (инвалидларның) читләр каравына индивидуаль ихтыяҗын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 9 сентябрендәге 646 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атамасында «читләр» сүзен төшереп калдырырга;

преамбулада «система турында» сүзләрен «системаны булдыру буенча сынау проектын гамәлгә ашыру турында» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «читләр» сүзен төшереп калдырырга;

әлеге Боерык белән расланган Өлкән яшьтәге гражданнарның (инвалидларның) читләр каравына индивидуаль ихтыяҗын билгеләү кагыйдәләрендә:

атамасында һәм текст буенча алга таба тиешле килеш кушымчаларында һәм саннарда бирелгән «читләр» сүзен төшереп калдырырга;

1.1 пунктта «система турында» сүзләрен «системаны булдыру буенча сынау проектын гамәлгә ашыру турында» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктта «система турында» сүзләрен «системаны булдыру буенча сынау проектын гамәлгә ашыру турында» сүзләренә алмаштырырга;

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Типлаштыруны уздыруда катнашучы учреждениеләр

Карауга мохтаҗ булган өлкән яшьтәге гражданнарга (инвалидларга) типлаштыруны уздыру Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре (алга таба – комплекслы үзәкләр) тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

3.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының муниципаль райондагы (шәһәр округындагы) социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) (алга таба – социаль яклау территориаль органына) социаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән, карауга мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарга (инвалидларга) типлаштыруны уздыру яки, медицина оешмасыннан, дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый оешмалардан өлкән яшьтәге гражданинның (инвалидның) карауга потенциаль мохтаҗ булуы турында мәгълүмат алынган очракта яисә «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасының «Татарстан Республикасында халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүне оештыру» ярдәмче системасының «Озак вакытлы карау системасы» модулендә сигнал картасы алынган очракта, карауга мохтаҗ булган өлкән яшьтәге гражданнар (инвалидлар) турында мәгълүмат алынган көннән башлап ике эш көне эчендә комплекслы үзәкләр хезмәткәрләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Социаль хезмәтләрдән файдаланучыларны планлы рәвештә типлаштыру елына бердән артык булмаган ешлыкта үткәрелә.»;

IV бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Типлаштыруны үткәрүче белгечләргә карата таләпләр

4.1. Типлаштыруны комплекслы үзәк белгече (социаль тернәкләндерү буенча белгеч, социаль эш буенча белгеч, психолог) (алга таба – типизатор) үткәрә.

4.2. Типизатор «Гражданинның социаль хезмәт күрсәтүгә индивидуаль ихтыяҗын билгеләү һәм тәрбияләүгә мохтаҗлык дәрәҗәсен билгеләү» һөнәри әзерлек (яңадан әзерләү) программасы буенча һөнәри белем алуны узарга һәм билгән вазыйфа буенча профессиональ стандарт таләпләренә туры килергә тиеш («Социаль эш буенча белгеч», «Социаль өлкәдә психолог», «Социаль тернәкләндерү белгече»).

4.3. Типизаторның тышкы кыяфәте гомуми кабул ителгән эш стиленә туры килергә тиеш, ул рәсмилеге, тыйнаклыгы, традиционлыгы, пөхтәлеге, дини атрибутикасы булмавы белән аерылып тора.

4.4. Өлкән яшьтәге гражданинга (инвалидка) хезмәт күрсәтә торган социаль хезмәткәр яки сиделка (карау буенча ярдәмче) тарафыннан типизация үткәрү рөхсәт ителми.»;

5.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.9. Типлаштыру барышында:

социаль, шул исәптән гаилә статусы бәяләнә;

түбәндәгеләр исәпкә алына:

1) социаль яклау территориаль органына ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында озак вакытлы карау системасында катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган белешмәләр нигезендә өлкән яшьтәге гражданинның (инвалидның) тормыш эшчәнлегендәге чикләмәләре һәм сәламәтлек торышы:

медик-социаль экспертиза нәтиҗәләре турында (гражданинда инвалидлык булган очракта);

медицина тикшерүләре, диспансерлаштыру һәм диспансер күзәтүе нәтиҗәләре турында;

медицина оешмаларында гражданинга уздырылган өстәмә тикшерү нәтиҗәләре турында;

2) өлкән яшьтәге гражданинның (инвалидның) гаилә әгъзаларының яисә аңа ярдәм күрсәтүче һәм (яисә) өлкән яшьтәге гражданин (инвалид) белән даими аралашуда булган башка затларның (туганнары, дуслары, күршеләре) мәгълүматлары.»;

5.10 пунктта:

өченче абзацта «бәяләү бланкы» сүзләрен «карауга индивидуаль ихтыяҗ булуын билгеләү бланкы» сүзләренә алыштырырга;

бишенче абзацта «бәяләү бланкы» сүзләрен «карауга индивидуаль ихтыяҗ булуын билгеләү бланкы» (алга таба – бланк) сүзләренә алыштырырга;

5.11 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«торак-көнкүреш һәм социаль шартларны тикшерү актындагы һәм бланктагы белешмәләр типизатор тарафыннан «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасының «Татарстан Республикасында халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүне оештыру» ярдәмче системасының «Озак вакытлы карау системасы» модуленә типлаштыруны уздырган көнне кертелә, торак-көнкүреш һәм социаль шартларны тикшерү акты һәм бланк кулдан кәгазь чыганака территориаль социаль яклау органы тарафыннан өлкән яшьтәге гражданинны (инвалидны) социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану (социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак танудан баш тарту) турында карар кабул итү һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү яисә социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын яңадан карау өчен территориаль социаль яклау органына тапшырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле VI бүлек өстәргә:

«VI. Типлаштыру сыйфатын контрольдә тоту

6.1. Типлаштыру сыйфатын контрольдә тоту Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Республика ресурс үзәге» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Ресурс үзәге) озак вакытлы карау системасын координацияләү бүлекчәсенең учреждение җитәкчесе раслаган график нигезендә «Карауга мохтаҗ булуны билгеләү методикасы» квалификация күтәрү программасы буенча һөнәри белем

алган белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.2. Типлаштыру сыйфатын контрольдә тоту түбәндәгеләрне үз эченә ала:

типлаштыруны уздыруның дөреслеген тикшерү максатларында, карауга индивидуаль ихтыяҗ булуын билгеләү бланкында каралган мәсьәләләр буенча кабат интервью үткәрү;

типизаторлар үткәргән интервью нәтиҗәләре буенча Ресурс үзәге белгечләре тарафыннан кабат уздырылган интервью нәтиҗәләре белән чагыштыру;

типлаштыру сыйфатын тикшереп тору нәтиҗәләре турында акт формалаштыру, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтүләрнең индивидуаль программасын яңадан карау буенча киңәшләрдән тора (алга таба – акт);

актны социаль яклау территориаль органына һәм планлы рәвештә беренче типлаштыруны уздырган комплекслы үзәккә җибәрү.

6.3. Социаль яклау территориаль органы, актта тиешле тәкъдимнәр булган очракта, социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын яңадан карауны тәэмин итә.».

Министр Э.Ә.Зарипова